


***Барысыда безнең кулда!***

# Максат:

Т*<u>әнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенең синквейн алымы белән таныштыру, дәресләрдә практик кулланырга өйрәтү</u>*

# Бурычлары:

- *укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру;*
- *укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;*
- *белем бирү процессын оптимальләштерү,*
- *белем алуга уңай омтылыш (мотивация) булдыру.*



Фикерләү сәләте проблемалы ситуацияләр аша,

бала предмет турында төшенчәләрне үзе эзләп

тапкан вакытта гына үсеш ала.

(Л.С.Выготский)

# Синквейнны язу тәртибе:

* 1 нче юл. Теманы ачыклаучы сүз, исем.
* 2 нче юл.  Синквейн темасына туры килә торган ике сыйфат.
* 3 нче юл. Синквейн темасына хас булган өч фигыль.
* 4 нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә. Ул укучының темага мөнәсәбәтен күрсәтергә тиеш.
* 5 нче юл. Укучының темага карата үз фикерен бер сүз белән чагылдырган нәтиҗә

Критик фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора:

- *өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту*
- *төшенү (аңлау)*
- *рефлексия.*

Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү һәм гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә (уку эшчәнлегенә) ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

* Төшенү (аңлау) этабында укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәрен яңалары белән бәйли, тулыландыра.
* Рефлексия этабында укучы өйрәнгәннәрне бербөтен итеп күзаллый,  яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.

Игътибарыгыз  өчен бик зур рәхмәт!